ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22 октябрь, 2015 ел № 2/12

Шәһәр Советының 2010 елның 26 маендагы 50/5 санлы Карары белән расланган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2010 елның 26 маендагы 50/5 санлы Карары (Шәһәр Советының 2010 елның 15 июлендәге 52/5, 2010 елның 26 августындагы 53/7, 2011 елның 27 гыйнварендәге 8/4, 2011 елның 25 августындагы 13/7, 2011 елның 27 октябрендәге 14/7, 2012 елның 20 декабрендәге 22/17, 2013 елның 31 октябрендәге 27/9, 2013 елның 19 декабрендәге 28/9, 2014 елның 10 июлендәге 31/6, 2014 елның 9 декабрендәге 35/7, 2014 елның 23 декабрендәге 36/5, 2015 елның 15 апрелендәге 39/7 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 бүлек үз көчен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге 14 бүлекне өстәргә:

«14 бүлек «Дезинфекцияләү станциясе» сәламәтлек саклау муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенең, белгечләренең, хезмәткәрләренең һәм эшче һөнәре буенча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү

51. «Дезинфекцияләү станциясе» сәламәтлек саклау муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – «Дезинфекцияләү станциясе») җитәкчесенең, белгечләренең, хезмәткәрләренең (алга таба – хезмәткәрләр) һәм эшче һөнәре буенча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләренең (алга таба – эшчеләр) хезмәтләренә түләү

түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

1) вазифаи оклад (хезмәт хакы ставкасы);

2) стимуллаштыру характерындагы түләүләр;

3) компенсация характерындагы түләүләр.

52. Хезмәткә түләү фонды шәһәр бюджетыннан күчерелүче субсидияләр күләменнән һәм башка керем китерә торган эшчәнлектән керүче средстволардан чыгып формалаша.

53. «Дезинфекцияләү станциясе» җитәкчесенең һәм хезмәткәрләренең, эшчеләренең уртача хезмәт хакының чик нисбәте икегә кадәр кабатлылыкта билгеләнә.

54. Хезмәткәрләрнең вазифаи оклад күләме тәшкил итә:

| Вазифа исеме | Оклад, сумнарда |
|---|---|
| Директор | 14 450,00 |
| Баш бухгалтер | 11 560,00 |
| Баш икътисадчы | 9 849,00 |
| Кадрлар бүлеге башлыгы | 8 497,00 |
| Баш бухгалтер урынбасары | 7 956,00 |
| Бухгалтер | 5 953,00 |
| Икътисадчы | 5 953,00 |
| Инженер - программист | 5 953,00 |
| Электрон-хисаплау машинасы өлкән операторы | 5 791,00 |
| Диспетчер | 5 676,00 |
| Учак дезинфекциясе бүлеге мөдире | 8 748,00 |
| Табиб - эпидемиолог ярдәмчесе | 6 831,00 |
| Инструктор - дезинфектор | 6 831,00 |
| Медицинский дезинфектор | 6 415,00 |
| Профилактика дезинфекциясе бүлеге мөдире | 8 748,00 |
| Табиб - дезинфектолог | 8 331,00 |
| Лаборант | 6 831,00 |

55. Эшчеләрнең вазифаи оклад күләме:

| Вазифа исеме | Оклад (хезмәт хакы ставкасы), сумнарда |
|---|---|
| Махсус киемне юу һәм төзәтү буенча машинист | 5 965,00 |
| Балта остасы | 5 965,00 |
| Биналарны җыештыручы | 5 965,00 |
| Слесарь - сантехник | 5 965,00 |
| Каравылчы | 5 965,00 |
| Автомобиль йөртүче | 6 084,00 |

56. «Дезинфекцияләү станциясе» хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләргә керә:

1) катлаулылык һәм киеренкелек өчен окладтан 10 процент күләмендә түләү;

2) башкарылган хезмәт вазифалары нәтиҗәләре буенча башкарылган

эшнең сыйфаты өчен окладтан 15 процент күләмендә түләү, «Дезинфекцияләү станциясе» җитәкчесе өчен баланс комиссиясе тарафыннан, башка хезмәткәрләр өчен «Дезинфекцияләү станциясе» тарафыннан төзелгән комиссия тарафыннан билгеләнә;

3) эш стажы өчен түләү:

| Эш стажы | Өстәмә күләме |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артык | 20 |

4) белгечләргә квалификацион категория өчен:

| Квалификацион категория | Өстәмә күләме |
|---|---|
| Югары квалификацион категория | 20 |
| 1 нче квалификацион категория | 10 |
| 2 нче квалификацион категория | 6 |

5) әлеге Нигезнамәнең 59 пункты һәм Башкарма комитет карары һәм Дезинфекцияләү станциясе»нең локаль акты белән расланучы учреждение эшчәнлегенең нәтиҗәлелек критерийләре нигезендә исәпләнүче премия.

57. «Дезинфекцияләү станциясе» хезмәткәрләренә һәм эшчеләренә компенсация характерындагы түләүләргә керә:

1) зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен түләүләр;

2) нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен түләүләр.

Кичке вакытта эшләгән һәм зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен түләүләр күләме РФ хезмәт законнары белән билгеләнә.

Вакытлыча булмаган хезмәткәрнең яисә эшченең вазифаларын хезмәт килешүе белән билгеләнгән эштән азат ителмичә башкарганда, тиешле хезмәткәргә яки эшчегә булмаган хезмәткәрнең яки эшченең вазифасы буенча вазифаи окладтан (хезмәт хакы ставкасыннан) 50 процент күләмендә өстәмә түләү билгеләнергә мөмкин.

58. «Дезинфекцияләү станциясе» эшчеләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләргә керә:

1) әлеге Нигезнамәнең 59 пункты нигезендә премия;

2) машина йөртүчеләргә классына карап:

- 1 нче класс машина йөртүчеләргә – 25 процент;
- 2 нче класс машина йөртүчеләргә – 10 процент.

59. Хезмәткәрләргә һәм эшчеләргә премия түләүләре өчен каралган хезмәткә түләү фондының күләме вазифаи окладлар (хезмәт хакы ставкалары) түләү өчен һәм төп эш урыны һәм төп вазифа буенча стимуллаштыру түләүләре өчен каралган хезмәткә түләү фондыннан ике процентан да ким түгел.».

2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә, әлеге Карарның 1 пункты 1 пунктчасыннан тыш.

1 пунктның 1 пунктчасы 2016 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшерүне Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев